**Татарстан Республикасы Хисап палатасы**

# Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2021 елдагы эшчәнлеге турында хисап

Казан – 2022 ел

# Эчтәлек

Тикшерү-ревизия эшчәнлеге......................................................3

Экспертиза-аналитик эшчәнлек..................................................17

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы, Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек, халыкара хезмәттәшлек ..............................................28

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары, Россия Федерациясе Муниципаль тикшерү-хисап органнары берлеге белән үзара хезмәттәшлек ..............................................32

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек ..............................................33

Эшчәнлектә хәбәрдарлык..............................................36

# Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2021 елдагы эшчәнлеге турында хисап

Татарстан Республикасы Хисап палатасы (алга таба – Хисап палатасы) эшчәнлеге турында Хисап 2004 елның 7 июненнән «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 37-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 33 маддәсе нигезендә әзерләнде.

Хисапта 2021 елда законнарда билгеләнгән бурыч һәм вәкаләтләрне үтәү буенча Хисап палатасы эшчәнлеге нәтиҗәләре тәкъдим ителде.

## Тикшерү-ревизия эшчәнлеге

Хисап елында Хисап палатасы 45 тикшерү-ревизия чарасы үткәрде, 384 объектны тикшерде.

Татарстан Республикасы бюджетының түбәндәге илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чараларын куллануны тикшерү кысаларында тикшерүләр үткәрелде:

- «Экология» Татарстан Республикасы бюджетына урманнарны торгызу, урман торгызу өчен урман орлыклары запасларын формалаштыру өчен кергән субвенцияләрне куллану кысаларында;
- «Мәдәният» мәдәният өлкәсендә белем бирү оешмаларын (балалар сәнгать мәктәпләрен һәм училищеларын) музыка кораллары, җиһазлар һәм уку материаллары белән тәэмин итү өлешендә;
- «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм мәшгульлеккә ярдәм итү» предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруның модульле үрнәкләрен булдыру өчен предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга адреслы ярдәм күрсәтү кысаларында;
- «Демография» халыкка физик культура һәм спорт, массакүләм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, шул исәптән спорт

объектлары белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен арттыру чараларын гамәлгә ашыру кысаларында;

- «Мәгариф» сәләтле балаларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү үзәкләрен булдыру өлешендә;

- «Торак һәм шәһәр мохите» гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча Республика адреслы программасы чаралары кысаларында;

- «Кече һәм урта эшмәкәрлек һәм шәхси эшмәкәрлек инициативасына ярдәм».

Россия Федерациясе Хисап палатасы белән берлектә:

- «Экология» илкүләм проекты чараларын тормышка ашыруның барышына, шул исәптән аларны финанс белән тәэмин итүнең үз вакытында булуына, максат һәм бурычларга, контроль нокталарга ирешүгә, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллану өлешендә идарәнең сыйфатында мониторинг;

- «Кече һәм урта эшмәкәрлек һәм шәхси эшмәкәрлек инициативасына ярдәм итү» илкүләм проекты кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлеккә дәүләт ярдәме чараларына аудит;

- «Мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә иминиятләштерелгән затларның хокукларын яклау системасына анализ» экспертиза-аналитика чарасы;

- «Беренчел медицина-санитария ярдәмнең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү чараларына бәя» тикшерү чарасы.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәсе буенча ике тикшерү чарасы үткәрелде: Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) парклар һәм сәнәгать мәйданчыклары булдыруга һәм үстерүгә юнәлдерелгән дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелегенә аудит һәм авыр тормыш хәлендә калган балалар һәм яшүсмерләргә вакытлыча яшәү өчен билгеләнгән

социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануны тикшерү.

Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең эксперт төркеме составында Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында һәм ведомство карамагындагы учреждениеләрдә, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгында һәм «Татарстан Республика «Сәләт» яшьләр иҗтимагый фонды» КБО да, шулай ук Татарстан Республикасының Апас, Лаеш һәм Теләче муниципаль районнарында коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыруда практик ярдәм күрсәтү буенча комплекслы чаралар үткәрүдә катнашты.

Татарстан Республикасында Гомумроссия халык фронтының төбәк башкарма комитеты мөрәҗәгате буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында ятим балаларны торак белән тәэмин итү буенча бюджет чараларын куллануның аерым мәсьәләләрен тикшерү уздырылды.

Татарстан Республикасы прокуратурасы мөрәҗәгате буенча «Агропарк» проектын гамәлгә ашырганда бюджет чараларыннан нәтиҗәле файдалану; ышанычлы идарәгә бирелгән дәүләт мөлкәтеннән нәтиҗәле һәм максатчан файдалану; «Казан» агросәнәгать паркы» АҖ дә суыткыч җиһазларын сатып алу һәм эксплуатацияләүгә бирелгән чараларны файдалану тикшерелде.

Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссиянең эксперт төркеме составында Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында терроризмга каршы тору буенча профилактик эшнең торышын тикшерүдә катнашылды.

Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятенең Территориаль фонды (алга таба – Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды) бюджеты үтәлешенең, дәүләт һәм муниципаль милекне файдалануның аерым

мәсьәләләре буенча тикшерү чаралары Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгында, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында, «Таттелеком» ААҖ дә, Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, аның әйләнеше һәм сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясендә, Татарстан Республикасы Азнакай, Әлмәт, Баулы, Балтач, Чүпрәле, Кукмара, Мамадыш, Питрәч, Чистай муниципаль районнарында уздырылды.

Татарстан Республикасы «Татарстан фәнни-техник мәгълүмат үзәге» ДУП һәм Татарстан Республикасы «Татлизинг» ДУП нең финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерү үткәрелде.

Үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча гомуми күләме **3 427 458,8 мең сум** булган **хокук бозулар ачыкланды**, шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджеты чаралары буенча – 826 819,2 мең сум, муниципаль берәмлекләр бюджетлары буенча – 1 189 921,8 мең сум, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды – 48 173,9 мең сум, башка чаралар буенча – 1 362 543,9 мең сум.

**2021 елда үткәрелгән тикшерү чаралары барышында Хисап палатасы ачыклаган финанс бозулары төзелеше**

мең сумнарда




Тикшерү чаралары уздырганда түбәндәге бозулар ачыкланды:

- дәүләт һәм муниципаль милек белән идарә итү һәм файдалану өлкәсендә бозулар – 1 753,3 млн. сум;
- бухгалтерлык (бюджет) исәбен һәм хисаплылыкны бозу – 1 099,7 млн. сум;
- дәүләт (муниципаль) сатып алуларын гамәлгә ашырганда бозулар – 216 млн. сум;
- бюджетларны формалаштырганда һәм үтәгәндә бозулар – 212,2 млн. сум;

- бюджет чараларын һәм дәүләт милкеннән нәтиҗәсез файдалану – 142,8 млн. сум;
- бюджет чараларын максатсыз куллану – 3,4 млн. сум.

Хисап палатасы үткәргән тикшерү чаралары нәтиҗәләрен гомумиләштерү һәм анализлау түбәндәге системалы җитешсезлекләрне ачыкларга мөмкинлек бирә.

**Дәүләт һәм муниципаль милек белән идарә итү һәм эш итү өлкәсендә хокук бозулар – 1 753,3 млн. сум.**

*Мөлкәтне тиешле хокукый нигезләрдән башка өченче затларга файдалануга тапшыру.*

Татарстан Республикасының Әлмәт муниципаль районында гомуми күләме 71 889,9 мең сум булган район казнасы составына керүче инженерлык челтәрләре (су белән тәэмин итү, канализация, җылылык белән тәэмин итү һәм электр белән тәэмин итү челтәрләре) килешү мөнәсәбәтләрне рәсмиләштермичә, коммерциячел структуралар тарафыннан файдаланыла.

Татарстан Республикасының Балтач муниципаль районында гомуми бәясе 17 773 мең сум булган муниципаль милек объектларыннан (су һәм газ белән тәэмин итү челтәрләре), тиешле шартнамәләр төземичә, коммерциячел оешмалар файдалана.

«Диализ клиникасы» ҖЧҖ (Казан шәһәре), концессион килешүнең гамәлдә булу вакыты чыккач, гомуми бәясе 7 018,1 мең сумлык медицина җиһазларын (гемодиализ аппаратлары, диализлаучы эретмәләр концентратларын әзерләү җайланмасы, матди кыйммәтләр) тиешле халәттә дәүләт милкенә кире кайтармаган.

*Дәүләт милкен хуҗалык әйләнешенә кертү буенча чаралар күрмәү.*

Физик культура һәм спорт, массакүләм спорт белән шөгыльләнү өчен халыкка шартлар тудыру, шул исәптән «Демография» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында спорт объектлары белән тәэмин итү дәрәҗәсен арттыру чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелегенә аудит барышында төрле спорт объектларында (Питрәч авылында спорт

мәйданчыгы, Яр Чаллы шәһәрендә физкультура-сәламәтләндерү комплексы, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы бистәсендә спорт залы) 10 268,6 мең сумлык җиһаз комплектларының монтажланмавы һәм файдаланылмавы ачыкланды.



*Питрәч авылындагы спорт мәйданчыгында җиһазлар комплекты монтажланмаган*



*Хисап палатасы тикшерүе нәтиҗәләре буенча җиһазлар монтажланды*

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика туберкулезга каршы клиник диспансеры» ДАССУ се озак вакыт дәвамында гомуми бәясе 37 341,7 мең сум булган дәүләт милкен (административ биналар, лаборатория бинасы, флюорография җиһазлары белән җиһазландырылган автомобильләр, медицина җиһазлары һәм медицина билгеләнешендәге әйберләр) файдаланылмый.

*Җир ресурслары белән идарә итү һәм куллануга бәйле бозулар.*

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында гомуми мәйданы 3 384,2 га, кадастр бәясе 26 786,5 мең сум булган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән, тиешле хокукны билгеләүче документларны рәсмиләштермичә, коммерциячел оешмаларның файдалану фактлары ачыкланган, нәтиҗәдә, район бюджетына гомуми күләме 201,6 мең сум булган аренда түләве алынып бетмәгән.

**Бухгалтерлык (бюджет) исәбе һәм хисаплылыкны бозулар.**

«Республика олимпиада үзәге» ДАББУ ндә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан гомуми бәясе 277,4 мең сум булган коммерциячел оешмалар белән дәүләт контрактлары кысаларында тапшырылган программа тәэмин ителешен куллануга бердәнбер булмаган хокуклар бухгалтерлык исәбе буенча чагылдырылмаган.

Балтач штб. Башкарма комитетында бухгалтерлык исәбендә Балтач муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән 2011 нче елда җирлек милкенә бирелгән фатирның 400,6 мең сум күләмендәге бәясе чагылыш тапмаган.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбендә чит юридик затларга бушлай куллануга, арендага бирелгән гомуми суммасы 113 643,2 мең сум булган мөлкәтнең бәясе чагылыш тапмаган.

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Советының бухгалтерлык исәбендә чынбарлыкта шәхси затка сатылган 1 050,6 мең сумлык «Ауди А6» автомобиле санала.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетында «Сельхозжилсервис» МУП нән муниципаль милектән түләүсез файдалану килешүе буенча алынган бәясе 3 327,8 мең сум булган Toyota Camry автомобиле саналмый.

Бюджет исәбенә, шул исәптән бюджет хисабын төзү, бирүгә закон таләпләрен бозу фактлары буенча административ хокук бозулар турында 41 беркетмә төзелде.

**Дәүләт (муниципаль) сатып алуларын гамәлгә ашырганда хокук бозулар.**

*Контрактлар (килешүләр) шартларына туры килми торган китерелгән товарларны, башкарылган эшләрне, хезмәтләрне кабул итү һәм түләү.*

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Олимпия резервы спорт мәктәбе» МБУ дәүләт контрактлары кысаларында муниципаль контрактлар шартларына туры килми торган 525,7 мең сумлык спорт киемнәре белән тәэмин ителгән (спорт костюмнарына тәүлекнең караңгы вакытында күренүчәнлекнең югары дәрәҗәсен тәэмин итә торган яктылык кайтаргыч хәрефләр төшерелмәгән).

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы учреждениеләрне тәэмин итүче («Одэкс» ҖЧҖ) дәүләт контракты шартларына тулысынча туры килми торган технологик җиһаз куйган.

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты, төзелгән контракт шартларын бозып, каралган эшләрне чынбарлыкта тәмамлауга кадәр коммерциячел оешмага («Татнефтедор» ҖЧҖ) 6 003,2 мең сум күләмендә түләүне гамәлгә ашырган.

*Тәэмин итүчеләр (башкаручылар) килешүләр шартларын үтәмәгән очракта дәүләт һәм муниципаль заказчылар тарафыннан чаралар күрмәү.*

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының аерым авыл җирлекләре башкарма комитетлары «Мирэкл» ҖЧҖ нән төзелгән контрактлар шартларына туры килми торган (өстәмә җиһазлары булмаган) гомуми бәясе 2 915,4 мең сум булган тракторлар кабул ителгән.

«Татарстан Республикасының инвестиция-төзелеш баш идарәсе» ДКУ балалар сәламәтләндерү лагерьларында реконструкцияләү һәм капиталь ремонт буенча төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга дәүләт контрактлары буенча җаваплылык чараларын кулланмый, тәэмин итүчеләр һәм подрядчы оешмаларның йөкләмәләрен тиешенчә

үтәмәгәннәре өчен гомуми күләме 6 179,4 мең сум булган неустойка (штраф, пеня) түләү таләбе гамәлгә ашырылмый.

«Мәдәният» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында мәдәният өлкәсендә белем бирү оешмаларын (балалар сәнгать мәктәпләрен һәм училищеларын) музыка кораллары, җиһазлар һәм уку материаллары белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануны тикшерү нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы музыка учреждениеләренә коммерциячел оешманың («Гармоника» ҖЧҖ) гомуми бәясе 1 650 мең сумлык техник яктан төзек булмаган музыка җиһазлары (аккордеон, баян, гөслә) кайтаруы ачыкланды.

*Сатып алу турында төп нигезләмәләр һәм принципларны үтәмәү.*

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы хуҗалык-эксплуатация хезмәте» МБУ тарафыннан 488,5 мең сумлык килешү аны төзегән датадан алдарак эш башкару вакыты (берьеллык үсемлекләр утырту) белән төзелә.

«Экология» илкүләм проектын тормышка ашыру кысаларында урман торгызу мәйданын арттыруга, урман торгызу өчен урман орлыклары запасын булдыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануны тикшерү кысаларында «Мамадыш урман хуҗалыгы» ДБУ нең гомуми бәясе 928 мең сум булган утырту материалын (447 мең ылыслы токым үсентеләре) аны сатып алу өчен шартнамәләр төзүгә кадәр алуы ачыкланды.

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Мәдәният бүлеге» МБУ чараны тавыш һәм видео җиһазлары белән тәэмин итүгә хезмәтләр, туклану оештыру буенча, бәйрәм чарасы өчен бүләк җыелмалары белән тәэмин итүгә хезмәт күрсәтү буенча гомуми бәясе 425 мең сум булган килешүләрне чынбарлыкта хезмәт күрсәтү датасыннан соңрак төзи.

*Төзелеш эшләренең бәясен арттыру, башкарылмаган эшләр өчен түләү.*

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында Әгерҗе авылында ял итү зонасын төзекләндергәндә, Кәкре Елга авылында балалар бакчасын ремонтлау вакытында гомуми күләме 372,3 мең сум булган башкарылмаган эшләр кабул ителгән һәм түләнгән.

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Капиталь төзелеш үзәге» МУП кышкы чорда юлларны һәм тротуарларны карап тоту буенча эшләрнең бәясен 1 276,4 мең сумга арттырган.

«Татарстан Республикасының инвестиция-төзелеш баш идарәсе» ДКУ балалар сәламәтләндерү лагерьларын реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау вакытында гомуми күләме 3 207 мең сум булган чынбарлыкта башкарылмаган төзелеш-монтаж эшләре кабул иткән һәм түләгән.



**Бюджетлар төзү һәм үтәү барышында бозулар**

*Дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүгә бюджет акчаларын нигезсез тоту, хезмәт хакын вакытында түләмәү.*

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тармак компетенциясендәге балалар санаторийларында («Черки Килдуразы» авылы Республика балалар шифаханәсе» ДАССУ, Казан шәһәре «Республика балалар психоневрология шифаханәсе» ДАССУ) учреждениеләр хезмәткәрләренә гомуми күләме 410,5 мең сум булган артык хезмәт хакы түләнгән.

Хисап палатасы үткәргән тикшерү нәтиҗәләре буенча «Черки Килдуразы» авылы Республика балалар шифаханәсе» ДАССУ юридик заты РФ КоАП 19.5 маддәсе 3 өлеше буенча 90 мең сум күләмендә

административ штраф рәвешендә административ җаваплылыкка тартылган.

«ТРда авыл хуҗалыгы кооперациясен үстерү буенча компетенция үзәге» ДБУ тарафыннан гамәлгә куючы (Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы) белән килешмичә генә учреждение җитәкчесенә гомуми суммасы 285,1 мең сум булган кызыксындыру характерындагы түләү башкарылган.

«Татарстан фәнни-техник мәгълүмат үзәге» ТР ДУП директорына, гамәлгә куючы белән килештермичә генә, гомуми күләме 80,1 мең сум булган түләү башкарылган.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Иске Чүпрәле күппрофильле лицее» МББУсендә кече һәм урта сыйныф укытучыларына лицей (өлкән) сыйныфларында эшләгән өчен 276,7 мең сум күләмендә нигезсез түләүләр (өстәмә түләүләр) башкарылган (мондый өстәмә түләүләр бары тик өлкән сыйныфлар укытучыларына гына каралган). Муниципаль районның «Прогресс» МУП директоры, эш нәтиҗәләре буенча җирле бюджетка керемнең бер өлешен күчерү буенча бурычы булганда, 41 мең сум күләмендә премиягә лаек булган.

«Татлизинг» ТР ДУП предприятиенең генераль директоры урынбасарларына билгеләнгән норматив күрсәткечтән артып киткән вазыйфаи окладны билгеләү нәтиҗәсендә гомуми суммасы 411,1 мең сум булган хезмәт хакын нигезсез түләгән.

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында «Сельхозжилсервис» МУП хезмәткәрләренә 10 011,9 мең сум күләмендәге хезмәт хакы билгеләнгән срокларны бозып (7 көннән 65 көнгә кадәр) башкарылган. Моннан тыш, предприятие җитәкчесенә салынган административ штрафлар, җәзаларны түләү, гаепле затның хезмәт хакыннан тиешле дәрәҗәдә тотып калмыйча, башкару битләре буенча түләү очраклары ачыкланды.

**Бюджет чараларыннан һәм дәүләт милкеннән нәтиҗәсез файдалану.**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сельхозжилсервис» МУП җитәкчесе тарафыннан эшчәнлегенең төп төре әлеге товарларны сату белән бәйле булмаган шәхси эшмәкәрдән «тере акчалар» исәбенә 305,3 мең сумлык торбалар сатып алынган. Акча тотылуның нигезлелеге расланмаган (фискаль-касса чеклары булмаган).

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында тикшерү барышында Звезда авыл җирлегендә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне, гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп хәл итүгә 445,6 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән бюджетара трансфертларның файдаланылмавы ачыкланды.

*Предприятиеләргә штраф һәм пеняләр рәвешендә өстәмә финанс йөкләнеше.*

«Татарстан фәнни-техник мәгълүмат үзәге» Татарстан Республикасы ДУП дә тикшерү заем чараларын кире кайтару буенча йөкләмәләрне тиешле дәрәҗәдә башкармау нәтиҗәсендә пеня һәм штрафлар түләүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән предприятиегә 600,4 мең сумлык өстәмә финанс йөкләнеше ачыкланган.

«Татлизинг» ТР ДУП тарафыннан Татарстан Республикасы буенча Суд приставлары федераль хезмәт идарәсенең башкарма кәгазьләре буенча штрафлар, суд карарлары буенча дәүләт пошлиналары, штрафлар, салым түләүләре буенча пеня, юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафлар, йөкләмәләрне үтәү вакыты чыккан өчен неустойка 309,6 мең сум күләмендә түләнгән. Күрсәтелгән чыгымнар предприятие табышының кимүенә йогынты ясаган.

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Водоканал» муниципаль казна предприятиесе тарафыннан салым

законнарын бозган өчен штрафлар, пенялар түләү өчен 1 376,6 мең сум күләмендә җирле бюджет чаралары кулланылган.

2021 елда Хисап палатасы үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча бюджет акчаларын тотканда, республика һәм муниципаль милектән файдаланганда гомуми күләме 3 113 945,7 мең сум булган (ачыкланган бозулар күләменең 90,9 проценты) ачыкланган финанс җитешсезлекләрен һәм кимчелекләрне бетерү буенча чаралар күрелде.

Хисап палатасы ачыклаган бозулар буенча министрлык һәм ведомстволар җитәкчеләренә, муниципаль берәмлекләр башлыкларына **41 күрсәтмә һәм 69 мәгълүмати хат** җибәрелде.

Барлык тикшерү чаралары материаллары Татарстан Республикасы Прокуратурасына җибәрелде.

**2 юридик һәм 24 вазыйфаи зат** административ җаваплылыкка тартылган, гомуми күләме **670 мең сум** булган штраф салынган.

Хисап палатасы һәм прокуратура органнары күрсәтмәләре буенча **28 вазыйфаи зат** дисциплинар җаваплылыкка тартылган.

**5 җинаять эше** кузгатылган.

Ике тикшерү чарасы нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары кабул ителгән:

– «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау тармагын үстерү» программасы буенча дәүләт шәхси партнерлыгын үстерүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануны тикшерү нәтиҗәләре буенча Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертелде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 31 маеннан 399 номерлы карары);

– Татарстан Республикасында җәмәгать юстициясе институтын үстерүгә бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү

нәтиҗәләре буенча «2014-2023 елларга Татарстан Республикасында юстицияне үстерү» дәүләт программасына дәүләт программасы нәтиҗәләрен бәяләү индикаторларын төгәлләштерү өлешендә үзгәрешләр кертелде (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 28 июненнән 504 номерлы карары).

**Экспертиза-аналитика эшчәнлеге**

Хисап вакыт аралыгында Хисап палатасы түбәндәгеләрне үткәрде:

- «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы бюджеты турында» һәм «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятенең Территориаль фонды бюджеты турында» закон проектларына экспертиза (2 бәяләмә);

- 2020 елга Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү (бәяләмә әзерләнгән);

- 2020 елга Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны тикшерү (бәяләмә әзерләнгән);

Татарстан Республикасы законнары проектларына экспертизалар (19 бәяләмә әзерләнгән);

- Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларына, гамәлдәге дәүләт программаларына кертелә торган үзгәрешләр проектларына экспертиза ясау (6 бәяләмә әзерләнгән);

- Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлешенең мониторингы. Квартал саен мониторинглар барышында касса чыгымнарына һәм Татарстан Республикасы дәүләт программаларын һәм төбәк проектларын гамәлгә ашыруга каралган бюджет билгеләнешләренең үтәлеше дәрәҗәсенә анализ ясалды (6 бәяләмә әзерләнгән).

Бәяләмәләр Хисап палатасы Коллегиясе тарафыннан расланган һәм закон таләпләре нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына,

Татарстан Республикасы Президентына тапшырылган. Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларына (дәүләт программаларына үзгәрешләр кертү проектларына) бәяләмәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде.

Бәяләмәләрдә чагылыш тапкан нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр закон проектларын икенче укылышта караганда, дәүләт программалары проектларын (дәүләт программаларына үзгәрешләр кертү проектларын) эшләп бетергәндә файдаланылды.

Татарстан Республикасы бюджеты турында закон проектына, республиканың территориаль дәүләт бюджеттан тыш фондлары бюджетлары турындагы закон проектларына, республика бюджеты турындагы законга һәм республиканың бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары турындагы законнарга үзгәрешләр кертү турындагы закон проектларына экспертиза ясау вәкаләтләре кысаларында түбәндәгеләр үткәрелде:

- **«2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы бюджеты турында»** Татарстан Республикасы законы проектына экспертиза. Закон проектының закон таләпләренә туры килү мәсьәләләре каралды, бюджет проекты белән бирелгән исәп-хисапларга һәм документларга анализ ясалды.

Экспертиза бюджет проектын формалаштырганда дефицит, резерв фонды күләме, дәүләт бурычы һәм аңа хезмәт күрсәтү чыгымнары күләме буенча билгеләнгән чикләүләрнең үтәлүен күрсәтте. 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы бюджетының төп параметрлары бюджет һәм салым законнары таләпләре нигезендә билгеләнгән.

2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар планлы вакыт аралыгына республика бюджеты проектын эшләгәндә нигез итеп алынган төп макроикътисадый күрсәткечләр фаразы Россия Федерациясе икътисады

үсешенең сценар шартларының «база» вариантын исәпкә алып формалаштырылды. Фаразда бюджет законнары таләпләре нигезендә 2021 елга республика бюджеты проектын төзегәндә кабул ителгән 2022-2023 елларга параметрлар тәгаенләнде һәм 2024 ел параметрлары өстәлде.

Республика бюджетының үз керемнәре күләме кабул ителгән сценар шартларда нигезләнгән һәм реаль.

Республика бюджеты проектының чыгым өлешен формалаштырганда бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең аерым категорияләренең хезмәт хакын арттыру исәпкә алынган, ачык норматив йөкләмәләрне үтәүгә чыгымнар индексацияләнгән.

Республика бюджеты чыгымнарының төп күләме программа форматында формалаштырылган. Аерым дәүләт программалары буенча бюджет проектында каралган финанслау күләмнәрендә һәм закон проекты белән тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы дәүләт программалары паспортларында (паспортлар проектларында) аермалар билгеләп үтелгән.

Төбәк состав өлешен финанслауга ассигнованиеләр күләме Татарстан Республикасының илкүләм проектларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслаштыруда федераль дәрәҗәдә билгеләнгән шартларны үтәүне тәэмин итә.

2022-2024 елларга республика бюджеты проекты бюджетның баланслылыгы һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән бюджет чыгымнарының гомуми җыелма каплау принципларын исәпкә алып формалаштырылган.

- **«2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында»** Татарстан Республикасы законы проектына экспертиза, аның нәтиҗәләре буенча закон проектының бюджет законнары

таләпләрен исәпкә алып формалашуы билгеләп үтелде. Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты балансланган – керемнәр һәм дефицитны финанслау чыганакларыннан кертемнәр күләме планлаштырыла торган чыгымнар күләменә туры килә.

Хисап палатасы Бәяләмәсендә Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджетының аерым чыгымнары буенча максатчан маддәләрнең атамаларын төгәлләштерү буенча бирелгән тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты проектын икенче укылышта караганда исәпкә алынды.

- **«2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы бюджеты турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында»** ике закон проектына экспертиза.

Кертелә торган үзгәрешләр үз керемнәре буенча фараз күрсәткечләрен төгәлләштерү, кире кайтарылмый торган керемнәр күләмен, әлеге чаралар хисабына һәм максатчан чараларның калдыклары хисабына тотыла торган чыгымнарны тәгаенләштерү, бюджет ассигнованиеләрен дәүләт программалары, бюджет акчаларын баш бүлүчеләр арасында яңадан бүлү зарурлыгына бәйле иде. Бюджет күрсәткечләренә төзәтмәләр керткәндә бюджет законнарында билгеләнгән чикләүләр һәм таләпләр үтәлгән.

- **«2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында»** Татарстан Республикасы Законының ике проектына экспертиза. Хисап палатасы Бәяләмәләрендә составы һәм эчтәлеге буенча закон проектларының бюджет законнары

таләпләренә туры килүе билгеләп үтелә. Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фондының нормалаштырылган иминият запасы чаралары һәм аны куллану юнәлешләре 2010 елның 29 ноябреннән «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 326-ФЗ номерлы федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып төзәтелде.

Республика дәүләт хакимияте органнарының республиканың чыгым йөкләмәләренә кагылышлы яисә республика бюджеты һәм бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетларының керемнәрен үзгәртүгә китерә торган өлешендә, шулай ук дәүләт программалары проектларын һәм башка норматив хокукый актларын экспертизалау буенча вәкаләтләр кысаларында хисап елында түбәндәгеләр башкарылган:

- **«2020 елга Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында»** һәм **«2020 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында»** Татарстан Республикасы законнары проектларына экспертизалар һәм аларның күрсәткечләренең Хисап палатасы тикшерүен узган Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисаплар күрсәткечләренә туры килүе расланган. Бәяләмәләрдә законнар проектлары һәм аларга кушымталарның төзелеше һәм эчтәлеге буенча бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләрне саклап формалаштырылуы билгеләп үтелә;

- **«Оешмалар милкенә салым турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»** (5 закон проекты), **«Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү**

**турында»** (2 закон проекты), **«Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү турында»** (2 закон проекты), **«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» һәм «2022 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында»** Татарстан Республикасы законнары проектына экспертизалар. Бәяләмәләрдә закон проектларының законнар таләпләренә туры килүе һәм кертелә торган үзгәрешләрнең нигезлелеге турында нәтиҗә ясалды;

- **«2022 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында»** һәм **«2022 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында»** Татарстан Республикасы законнары проектларына экспертиза. Бәяләмәләрдә финанс чыгымнары нормативларының белем бирү оешмалары персоналына хезмәт өчен түләү чыгымнарының 5 процентка артуын исәпкә алып формалаштырылуы билгеләп үтелә. Белем бирү процессын уку әсбаплары, укыту һәм тәрбия чаралары белән тәэмин итүгә чыгымнар 2021 ел дәрәҗәсендә каралган;

- 2022-2024 елларда гамәлгә ашыру каралган **«Цифрлы Татарстан»** дәүләт программасы проектына экспертиза, аның нәтиҗәләре буенча программа проектының аерым индикаторлары

буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә Халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт биреме «Мәгълүмат инфраструктурасы» төбәк проекты паспорты, «2014-2025 елларга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасы белән расланган күрсәткечләргә туры килмәве билгеләнде.

Хисап палатасы билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүне объектив бәяләүне тәэмин итү өчен, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең ачыклыгы дәрәҗәсен арттыру» чарасы буенча индикаторның планлы күрсәткечләре өлешендә дәүләт программасы проекты нигезләмәләрен төгәлләштерергә тәкъдим итте;

- **«Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү»** дәүләт программасы проектына экспертиза, аның нәтиҗәләре буенча программаның аерым финанс күрсәткечләренең эчке килешмәве, программа чараларын гамәлгә ашыру өчен бюджеттан тыш чараларны җәлеп итү механизмының тасвирламасы булмавы ачыкланды. Сәнәгатьне үстерү буенча төбәк программаларын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен финанслаштыруның федераль дәрәҗәдә билгеләнгән шартларын үтәү максатларында, аерым индикаторларны дәүләт программасына кушымтада чагылдыру мәсьәләләрен өстәмә рәвештә эшләргә тәкъдим ителде.

Шулай ук Хисап палатасы тарафыннан «Гражданлык билгеләнешендәге төяп җибәрелгән продукция күләменең артуы» күрсәткеченә ирешүне тикшерүдә тоту, программаны тормышка ашыруның социаль-икътисадый нәтиҗәлелеген бәяләү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән тәкъдимнәр әзерләнде;

- **«2014-2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү»** дәүләт программасына үзгәрешләр проектына экспертиза. Хисап палатасы тарафыннан республиканың дәүләт белем бирү оешмаларының, урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге (кураторлык) өчен айлык акчалата түләүләрне тәэмин итү буенча программага кертелә торган чараны финанслау күләмнәренең нигезлелеге расланды. Хисап палатасы Бәяләмәсендә дәүләт программасын яңа программа чарасының үтәлеше дәрәҗәсен характерлаучы индикатор белән тулыландырырга тәкъдим ителде;

- **«Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2020-2023 еллар)»** дәүләт программасына үзгәрешләр проектына экспертиза. Бәяләмәдә дәүләт программасы паспортында һәм аңа кушымтада күрсәтелгән аерым үзара бәйләнешле күрсәткечләрнең килештерелмәве билгеләп үтелде, кайбер чаралар буенча нәтиҗәлелек индикаторлары белән бәйләнештәге финанслау күрсәткечләрен өстәмә эшкәртү кирәклеге күрсәтелде.

Программаны тормышка ашыруның ахыргы нәтиҗәләрен тикшерүдә тоту һәм нәтиҗәлелеген бәяләү өчен шартлар тудыру максатыннан, Хисап палатасы берничә программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләренә бәйле булган җыелма күрсәткечләрне билгеләүгә якын килүне эшләргә тәкъдим итте;

- **«2014-2023 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру»** дәүләт программасына үзгәрешләр проектына экспертиза, аның нәтиҗәләре буенча республиканың башка дәүләт программалары чаралары белән дәүләт программасы чараларын кабатлау очраклары ачыкланды. Бәяләмәдә билгеләп үтелгәнчә, аерым программа чаралары буенча индикаторларның план күрсәткечләрен билгеләүгә карата кулланылган алым аларны гамәлгә ашыру

нәтиҗәлелеген бәяләүне арттыру куркынычын тудыра. Дәүләт программасын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләгәндә күрсәткечләрнең чагыштырырлык булуы өчен, программа нигезләмәләрен гамәлгә ашыруның көтелә торган соңгы нәтиҗәләре өлешендә трактлау вариативлыгын юкка чыгару буенча үзгәрешләр проектын эшләп бетерергә тәкъдим ителде;

- **«2015-2024 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү»** дәүләт программасына үзгәрешләр проектына экспертиза, аның нәтиҗәләре буенча дәүләт программасы паспортында һәм кушымтада тәкъдим ителгән аерым бер-берсенә бәйле нигезләмәләрнең килешмәве, шулай ук планлы индикаторларны өстәмә эшкәртү кирәклеге билгеләп үтелде. Хисап палатасы бәяләмәсендә дәүләт программасын тормышка ашыру нәтиҗәлелегенә аны гамәлгә ашыруның барлык этапларында да бәя бирү үткәрү өчен шартлар тудыру һәм программа чараларының максатлары һәм бурычлары белән килешүен тәэмин итү максатларында дәүләт программасын этаплап гамәлгә ашыру механизмын куллану мөмкинлеген карарга тәкъдим ителде.

Хисап елында Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасының бюджеттан тыш территориаль дәүләт фондлары бюджетлары үтәлешенең оператив анализы һәм үтәлешен оештыруны тикшерүдә тоту кысаларында мониторинглар уздырылды һәм 2021 елның 1 кварталында, 1 яртыеллыгында һәм 9 ай эчендә Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында тиешле бәяләмәләр әзерләнде.

Мониторинглар кысаларында салым һәм салым булмаган керемнәр килүнең тулылыгына һәм үз вакытында керүенә, күләме һәм структурасы буенча чыгымнарның үтәлешенә, бюджетлар дефицитын финанслау чыганакларыннан җәлеп ителгән чараларның күләмнәренә,

алдагы елның шул ук чоры белән чагыштырганда бюджетлар үтәлешенең төп күрсәткечләре динамикасына анализ ясалды. Татарстан Республикасының ачык норматив йөкләмәләрен, дәүләт программаларын гамәлгә ашыру чыгымнарын вакытында финанслау, республика муниципаль берәмлекләре бюджетларына трансфертлар бирү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Резерв фонды чараларын тоту, дәүләт бурычының һәм аңа хезмәт күрсәтү чыгымнарының торышы мәсьәләләре каралды.

Шулай ук Бәяләмәләрдә региональ проектларны гамәлгә ашыруга касса чыгымнары күләмнәрен системалы рәвештә анализлау, планлаштырылган максатчан күрсәткечләргә ирешү, аларны гамәлгә ашыруны тәэмин итү, федераль бюджеттан финанслаштыру шартларын саклау максатларында республика дәүләт хакимияте органнары тарафыннан норматив хокукый актларны үз вакытында кабул итү нәтиҗәләре дә күрсәтелде.

Республика бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны, республиканың территориаль дәүләт бюджеттан тыш фондлар бюджетларының үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында 2021 елда **2020 елга Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында Хисап**ны һәм **2020 елга Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында Хисап**ны тышкы тикшерү башкарылды. Тикшерү нәтиҗәләре буенча бюджет үтәлеше турындагы еллык хисапларда дөрес булмаган яки тулы булмаган чагылыш фактлары ачыкланмады.

Тышкы тикшерүгә тәкъдим ителгән 2020 елга республика бюджеты үтәлеше турында Хисап, шулай ук бюджет акчалары баш администраторларының еллык бюджет хисаплылыгы еллык бюджет хисаплылыгын төзү һәм бирү тәртибен көйли торган норматив хокукый актлар нигезләмәләрен исәпкә алып формалаштырылды.

2020 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы Хисап күрсәткечләре бюджет чараларының баш администраторларының еллык бюджет хисаплылыгы күрсәткечләре белән расланган.

Бәяләмәдә керемнәр, чыгымнар, дефицитны финанслау чыганаклары буенча бюджетны оештыруны һәм үтәүне бәяләү, шулай ук чынбарлыктагы күрсәткечләрнең расланган билгеләнешләрдән читкә китү сәбәпләрен анализлау нәтиҗәләре тәкъдим ителде.

Республика бюджеты гамәлдәге законнарны саклап үтәлгән, 2020 елда чыгым йөкләмәләрен нигезсез кабул итү һәм бюджетның финанс ресурслары белән тәэмин ителмәгән кредит бурычларын барлыкка китерү фактлары билгеләнмәгән.

2020 елда республика бюджетыннан төбәк проектларын гамәлгә ашыруга чаралар федераль хакимият органнары белән төзелгән килешүләр нигезендә бүлеп бирелгән. Төбәк проектларын гамәлгә ашыруга каралган бюджет ассигнованиеләре 97,8 процентка үтәлгән, бу, нигездә, чаралар бирүнең башлыча гариза нигезендә, капиталь төзелешнең аерым объектларын төзү срокларын озайту, дәүләт заказын урнаштырганда бәйге процедуралары нәтиҗәләре буенча барлыкка килгән бюджет акчаларын экономияләү белән бәйле.

Хисап палатасы эшчәнлеген **методологик яктан тәэмин итү** кысаларында 2021 елда «Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеген планлаштыру» эшчәнлекне оештыру стандарты актуальләштерелде. Стандартның яңа редакциясендә Хисап палатасы Регламентына һәм законнарга кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынды.

# Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары Советы, Россия Федерациясе субъектларының тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек, халыкара хезмәттәшлек

2021 елда Хисап палатасы Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары Советы (алга таба – Совет), региональ тикшерү-хисап органнары белән хезмәттәшлекне үстерү һәм ныгыту эшен дәвам итте.



Идел буе федераль округында Совет бүлеген җитәкләүче Хисап палатасы Рәисе А.И. Демидов 2021 елга эш планы кысаларында ел дәвамында Совет һәм аның Идел буе федераль округындагы бүлеге эшне координацияләде.

Хисап елында Хисап палатасы вәкилләре Россия Хисап палатасы тарафыннан Россия Федерациясе субъектларының тикшерү-хисап органнары рәисләре, аудиторлары һәм инспекторлар составы өчен видеоконференция режимында үткәрелгән тәҗрибә уртаклашу буенча 45 укыту семинарында, шул исәптән халыкара: Россия-Кытай, Россия-Бразилия, Россия-Казахстан, Россия-Венгрия семинарларында катнаштылар.

Дистанцион укыту кысаларында түбәндәге актуаль мәсьәләләр каралды: тышкы дәүләт тикшерүен үстерүдә һәм нәтиҗәлелеген күтәрүдә цифрлы технологияләрне куллану; югары аудит органнары эшчәнлегенең ачыклыгы; яңа коронавирус инфекциясе белән бәйле финанс ярдәменең күрелә торган чаралары контекстында социаль өлкәдә аудит уздыру; тәмамланмаган төзелеш мониторингы һәм аның

күләмнрен киметү; дәүләт һәм муниципаль сатып алулар өлкәсендә коррупциягә каршы тору һәм башка мәсьәләләр.





Хисап палатасы вәкилләре Казахстан Республикасы бюджеты үтәлешен тикшерүдә тоту буенча Хисап комитеты оештырган «Яңа тарихи чынбарлык шартларында дәүләт аудиты системасы» темасына халыкара фәнни-гамәли онлайн конференциядә катнашты. Чарада Казахстан Президенты Администрациясе һәм Хөкүмәте вәкилләре белән беррәттән 27 чит илдән аудитның югары органнары, халыкара оешмалар вәкилләре, галимнәр һәм экспертлар катнашты. Хисап палатасы аудиторы И.А. Мөбарәков докладчыларның берсе булды, ул «Гадәттән тыш хәлләр аудитында аудит югары органнарының роле һәм COVID-19 таләпләре» секциясендә хәзерге шартларда Татарстан Хисап палатасының эш тәҗрибәсе белән уртаклашты.

Хисап палатасы аудиторы А.А. Якупов Грозный шәһәрендә COVID-19 пандемиясе шартларында төбәкләрнең тышкы финанс тикшерүенең югары органнары эше тәҗрибәсе белән уртаклашу буенча Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнарының Бөтенроссия киңәшмәсендә катнашты.

Хисап палатасы вәкилләре әлеге авторитетлы оешма Рәисе буларак Россия Хисап палатасы оештырган ИНТОСАИ Югары аудит органнарының халыкара оешмасының беренче Халыкара фәнни-гамәли онлайн конференциясендә катнашты. Пленар сессияләр барышында гадәттән тыш хәлләр вакытында һәм аннан соң дәүләт секторы аудиты

органнары эшчәнлегенең бурычлары һәм өстенлекле юнәлешләре, онлайн белем бирү перспективалары һәм аның киләчәк аудиторларын формалаштырудагы роле турында фикер алышу узды.

Красноярск шәһәрендә Хисап палатасы аудиторы И.А. Мөбарәков «COVID-19 пандемиясе белән көрәшкә бүлеп бирелгән акчаларны тотуны финанс тикшерүе тәҗрибәсе» темасына Россия Федерациясе субъектларының тикшерү-хисап органнары вәкилләренең түгәрәк өстәлендә һәм Красноярск икътисадый форумы кысаларында «Пандемия шартларында тышкы дәүләт финанс тикшерүе: алынган тәҗрибә» темасына төбәкара конференциядә катнашты.

Аудитор, мәгълүмати-аналитик системаларны куллану һәм илкүләм проектларны тормышка ашыруны тикшереп тору тәҗрибәсе белән уртаклашып, конференциядә чыгыш ясаучыларның берсе булды.




Шулай ук Хисап палатасы аудиторы И.А. Мөбарәков Иркутск шәһәрендә «Иркутск өлкәсендә тышкы дәүләт тикшерүен камилләштерү» темасына федераль структуралар, хакимият башкарма органнары, Иркутск өлкәсе Закон чыгару җыелышы вәкилләре, Иркутск өлкәсе һәм Россия Федерациясе муниципаль тикшерү-хисап органнары җитәкчеләре катнашында Иркутск өлкәсе тикшерү-хисап органнары Советының хисап җыелышында катнашты. Үз чыгышында ул коллегаларына Татарстан Республикасы территориясендә илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган чараларны тотуны тикшереп торуны оештыру турында мәгълүмат бирде.

Моннан тыш, Санкт-Петербургта узган «Россия төбәкләрендә һәм шәһәрләрендә стратегик планлаштыру» XIX Бөтенроссия форумында

һәм Россия Федерациясе Федераль Җыенының Федерация Советында парламент тыңлауларында катнашты, аның барышында «Экология» милли проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре һәм перспективалары турында фикер алышты.




Тышкы финанс тикшерүенең региональ органнары Европа оешмасында (алга таба – ЕВРОРАИ) әгъзалык кысаларында Хисап палатасы аудиторы И.А. Мөбарәков «COVID-19 пандемиясе чорында тышкы дәүләт финанс тикшерүе региональ органнарының кыйммәте һәм файдасы» темасына Босния һәм Герцеговинада узган ЕВРОРАИ халыкара семинарында доклад белән чыгыш ясады.

## Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тикшерү-хисап органнары, Россия Федерациясе, Муниципаль тикшерү-хисап органнары берлеге белән хезмәттәшлек

Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары Советы эшчәнлеге кысаларында Хисап палатасы муниципаль тикшерү-хисап органнары белән хезмәттәшлекне тәэмин итү буенча эшен дәвам итте.

Муниципаль тикшерү-хисап органнарына тикшерү-ревизия һәм экспертиза-аналитика эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча оештыру, хокукый, методик, мәгълүмати ярдәм күрсәтелде. Барлык муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының тикшерү-хисап органнарына кураторлар – аудиторлар һәм Хисап палатасының структур бүлекчәләре җитәкчеләре беркетелде.

Ай саен муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары эшчәнлегенә мониторинг ясалды.

Дәүләт һәм муниципаль финанс тикшерүенең актуаль мәсьәләләре буенча алдынгы һөнәри тәҗрибәне өйрәнү максатыннан республика муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары вәкилләренең Россия Федерациясе Хисап палатасының укыту семинарларында, шулай ук Россия Федерациясе Муниципаль тикшерү-хисап органнары берлеге әгъзаларының Гомуми җыелышында һәм аның Президиумы утырышында катнашуы оештырылды.



Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советының видеоконференция форматында узган йомгаклау утырышында 2021 елга эш



нәтиҗәләре, тышкы дәүләт һәм муниципаль финанс тикшерүенең актуаль мәсьәләләре каралды, эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләре билгеләнде, «Татарстан Республикасының иң яхшы финанс тикшерүчесе» бәйгесенә йомгак ясалды.

## Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек

Хисап палатасы рәисе А.И. Демидов җитәкчелегендә Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы (алга таба – Ведомствоара координацияләү советы) эшчәнлеге кысаларында хисап елында финанс тикшерүе органнары һәм хокук саклау органнарының үзара хезмәттәшлеген үстерү буенча эш дәвам иттерелде.

Ведомствоара координацияләү советының узган утырышларында түбәндәге мәсьәләләр каралды һәм тикшерелде: 2020 елда финанс-бюджет өлкәсендә тикшерү эшчәнлеге нәтиҗәләре; дәүләт (муниципаль) катнашы булган унитар предприятиеләрнең һәм акционерлык җәмгыятьләренең финанс-хуҗалык эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген тикшерү нәтиҗәләре; Татарстан Республикасы территориясендә илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган чараларны тотуны тикшерүдә тоту; бюджет өлкәсе учреждениеләрен азык-төлек продуктлары белән тәэмин итү буенча контрактлар шартларын үтәүне тикшерү нәтиҗәләре; шулай ук җир

ресурсларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерү һәм башка мәсьәләләр.

Ел саен эштә кабатлануны булдырмау максатларында Ведомствоара координацияләү советы әгъзалары тарафыннан Тикшерү чараларының җыелма планы төзелә һәм раслана





Финанс-бюджет өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү һәм профилактикалау максатларында республика министрлыкларына, ведомстволар һәм муниципаль берәмлекләренә җибәрелгән дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе органнары ачыклаган бозуларны һәм җитешсезлекләрне анализлау һәм системалаштыру нәтиҗәләре буенча Бәяләмә әзерләнде һәм расланды.

Татарстан Республикасы бюджеты чараларыннан һәм дәүләт милкеннән файдаланганда финанс дисциплинасының торышы турында 2020 елда Ведомствоара координацияләү советында тәкъдим ителгән органнар тарафыннан үткәрелгән тикшерү чараларының нәтиҗәләре турында гомумиләштерелгән мәгълүмат Татарстан Республикасы Президентына җибәрелде.

Оператив мәгълүмат бирү һәм ачыкланган бозулар буенча чаралар күрү максатында квартал саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тикшерү чаралары нәтиҗәләре турында җыелма мәгълүмат җибәрелде.



VI чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 23 нче утырышында Хисап палатасы Рәисе урынбасары А.Ш. Вәлиев Хисап палатасының 2020 елдагы эшчәнлеге турында хисап тотты.

Хисап палатасы аудиторлары С.Е. Колодников һәм А.Ә. Якупов Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар комитеты утырышында катнашты һәм 2017-2019 елларда республика Парламенты йөкләмәсе буенча уздырылган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен махсус (коррекцион) мәктәп-интернатлар эшчәнлеген тәэмин итүгә бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудит һәм 2017-2019 елларда табигый ресурслардан файдаланган өчен түләүләрне администрацияләү буенча бюджет вәкаләтләренең үтәлешен тикшерү йомгаклары буенча докладлар белән чыгыш ясадылар.

Утырыш нәтиҗәләре буенча профильле министрлыкларга Хисап палатасы тарафыннан ачыкланган бозу һәм җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрү йөкләнде.

Хисап палатасы аудиторы И.А. Мөбарәков Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм ведомство карамагындагы учреждениеләр белән узган киңәшмәдә республиканың бюджет өлкәсе учреждениеләрендә Хисап палатасы ачыклаган азык-төлек продуктлары белән тәэмин итүчеләрнең контрактлар шартларын үтәү буенча хокук бозулары турында доклад белән чыгыш ясады.

Хисап палатасы аудиторы А.Ә. Якупов Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт

унитар предприятиеләре һәм акционерлык җәмгыятьләре җитәкчеләре белән үткәрелгән киңәшмәләрдә катнашты һәм чыгыш ясады.

Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе белән хезмәттәшлек кысаларында Хисап палатасы вәкилләре 2021 елда Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр өчен квалификация күтәрү программаларын үткәрүдә катнашты.

## Эштә хәбәрдарлык

2021 елда Хисап палатасы, Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләү советы һәм Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советы эшчәнлеге массакүләм мәгълүмат чараларында (интернет-басмаларда, газеталарда, журналларда, телевидениедә) даими яктыртылып торды.

Хисап чорында Хисап палатасы эшчәнлеге 208 материалда, шул исәптән федераль һәм региональ басмаларда: REGNUM, «РБК-Татарстан», «Татар-информ», «Альтаир» (Иркутск өлкәсе), «Документлар&фактлар» (Санкт-Петербург) мәгълүмат агентлыклары веб-сайтларында, «Бизнес Online» һәм «Реальное время» электрон газеталарында, «Idel.Чынбарлык», «Forbes Казахстан», Novgorod.ru, УралПолит.ги веб-сайтларында, Яндекс-яңалыклар, Mail.ru-яңалыклар интернет-порталларында, «InKazan», «Казан репортеры», ТатЦентр, «KazanFirst» интернет басмаларында, «Республика Татарстан» газетасы, «Аргументы и Факты», «Комсомольская правда», «Коммерсант» газеталарның төбәк басмаларында, «Татарстан24» һәм «ТНВ» телеканалларының яңалыклар чыгарылышларында тәкъдим ителде.

Хисап палатасы эшчәнлеге турында мәгълүмат шулай ук рәсми сайтта (https://sprt.tatar), Россия Федерациясе Хисап палатасы һәм Россия Федерациясе Тикшерү-хисап органнары порталында (https://portalkso.ru) урнаштырылды. 2021 елда Хисап палатасы сайтына 25 119 керү теркәлде.

Үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча йомгаклау документлары, Хисап палатасы эшчәнлеге хроникасы квартал саен Хисап палатасының мәгълүмат бюллетеньнәрендә бастырып чыгарылды, алар Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләү советы әгъзаларына җибәрелде.